# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

## 2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлегендә үзара салым кертү турында

**2022 елның 11 ноябре** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авылында гражданнар җыены карар итте:

1. 2023 елда Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Сөйки авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау (сатып алу, төяү, ташу, грунт һәм таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сөйки авылында грейдирование, юлларны кардан чистарту, (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу);
- Сөйки авылында Троица чиркәвен ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);
- Сөйки авылында контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу);
- Сөйки авылында зират коймасы (төзелеш материаллары сатып алу);

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Красноармейская ур., Авыл үзәге;
- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы Колхоз урамы, 16а йорты, китапханә бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Сөйки
авыл җирлеге Башлыгы П.В.Сорокин